**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№ 4675**
**12.09.2019**

Яр Чаллы шәһәре территориясен
җыештыру һәм яшелләндерү буенча
санитар-экологик айлык үткәрү турында

Шәһәрне санитар чистарту һәм аны алга таба төзекләндерүне тәэмин итү максатында, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясен җыештыру һәм яшелләндерү буенча санитар-экологик айлыкны 2019 елның 1 октябреннән 2019 елның 31 октябренә кадәр үткәрергә (алга таба – айлык).

2. Айлык оештыру һәм үткәрү буенча шәһәр штабы составын (алга таба – шәһәр штабы), кушымтада каралганча расларга.

3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә 2019 елның 1 октябренә кадәр срокта айлык үткәрү буенча чаралар планын әзерләргә.

4. Башкарма комитетның район хакимиятләре Башлыклары И.Н. Галимовка, А.И. Кисловка, В.Х. Харисовка:

1) шәһәрнең тиешле районнары территориясендә айлык оештыру һәм үткәрү буенча район штаблары төзергә һәм атна саен айлыкның барышы турында шәһәр штабына хисап бирергә;

2) шәһәрнең тиешле районнары территориясендә 2019 елның 1 октябренә кадәр табигать күренешләре, шул исәптән корылык нәтиҗәсендә һәлак булган, яки төзелеш һәм реконструкция сәбәпле алынган яшел утыртмаларны ачыклау эшен тәэмин итәргә;

3) айлык чорында яшел утыртмаларны торгызу буенча эшне оештырырга.

5. Яр Чаллы шәһәренең оешма һәм иҗтимагый берләшмәләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

1) җир законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән җир участокларында санитар җыештыруны һәм яшел утыртмаларны торгызуны тәэмин итәргә;

2) шәһәрнең яшел фондын торгызу буенча чараларда актив катнашырга һәм оештыру һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 12 сентябрендәге
4675 нче карарына
кушымта

Айлык оештыру һәм үткәрү буенча шәһәр штабы
составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Зуев Илья Сергеевич | шәһәр штабы рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 2. | Ситдыйков Салават Әнәс улы | шәһәр штабы рәисе урынбасары, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 3. | Әхмәтова Гөлнар Карл кызы | Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе |
| 4. | Галимов Искәндәр Нургаләм улы | Башкарма комитетның Үзәк районы Башлыгы |
| 5. | Жандарова Юлия Владимировна | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция» МКУ башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы |
| 6. | Исхаков Илмир Зөфәр улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 7. | Кислов Александр Иванович | Башкарма комитетның Комсомол районы Башлыгы |
| 8. | Кропотова Наталия Анатольевна | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 9. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 10. | Харисов Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның Автозавод районы Башлыгы |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова